**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Бәйрәкә авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

Бәйрәкә ав.

№ 54 17 ноябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советы карарларының үз көчләрен югалтуларын тану турында

2003 елның 06 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2007 елның 02 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»гы 25-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 13 ноябрендәге 16094019202300023 санлы хокукый экспертизасы бәяләмәсе нигезендә, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан РеспубликасыЮтазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2023 елның 19 сентябрендәге «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне бер кеше кулындагы башкарма орган буларак коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә (сәяси партиядән тыш) түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүенә рөхсәт бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»гы 30 санлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарын;

- Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2017 елның 8 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрне коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бер кеше кулындагы башкарма орган буларак яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүе» турындагы 6 санлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында

http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина